Н.П.Огарев исемендәге МГУ студенты, мошенникларга кредит рәсмиләштервне булдырмау сылтавы белән, алдаучыларга 450 мен сумнан артык акча кvчергән.
Зыян кvрvченен 2003 елгы гаризасыннан кvренгәнчә, кичке вакытта ана таныш булмаган номердан шалтырату килгән. Шалтыратучы vзен банкнын куркынычсызлык хезмәте хезмәткәре дип таныштыра һәм мошенникларнын ана кредит рәсмиләштерергә тырышулары турында хәбәр итә. Жинаятьчеләрнен законсыз гамәл-ләрен булдырмау очен, зыян кvрvче якындагы банкоматта, ялган хезмәткәр кvрсәтмәсе буенча, vз картасыннан барлык булган акчаларын, янәсе 475 994 сум кvләмендә, куркынычсыз банк счетына кvчергән. Шуннан сон мошенник элемтәгә чыгудан туктаган. Егет полициягә гариза белән морәжәгать иткән. Әлеге факт буенча Россия Эчке эшләр министрлыгынын «Чамзинский» тикшерvчеләре тарафыннан «мошенниклык» маддәсе буенча жинаять эше кузгатылган. Жинаятьчеләрнен шәхесен ачыклауга юнәлдерелгән тикшерv эшләре һәм оператив-эзләv чаралары vткәрелә.
Мордовия Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы гражданнарга бернинди очракта да банк картасы, оченче затлар кvрсәтмәләре буенча гамәлләр башкарырга ярамый, дип кисәтә.